# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Полянка авыл җирлеге составына керүче Александровка авылы

11 ноябрь 2019 ел. № 6

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Зур Полянка авыл җирлеге составына керүче Александровка торак пунктында гражданнар җыены

**Карар итте**:

1. 2020 елда Зур Полянка авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге чараларга юнәлдерергә:

-җирлек эчендәге юлларны карап тоту;

- җирлек эчендәге юлларны ремонтлау;

- торак пунктларда урамнарны яктыртуны карап тоту;

3. Әлеге карарны Зур Полянка авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы, Александровка авылы, Мирная урамы, 9А йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Полянка авыл җирлеге Александровка мәдәният йорты бинасында мәгълүмат стендында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Зур Полянка авыл җирлеге башлыгы М.Р. Афанасьева